| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 19 маендагы** **Чистай шәһәре** **№ 248**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
“Чистай Башкарма комитеты карарына
үзгәрешләр кертү турында”гы 2019 елның 27 февралендәге
100 номерлы “Учетка кую һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең
төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын)
гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына
балаларны кертү” раслау турында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 2012 елның 29декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы “Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының якынча формасын раслау турында”гы 2015 елның 10 мартындагы 1389/15 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 27 февралендәге 100 номерлы карары (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 173 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең | Учетка кую өлешендә:<br>- бала туу турындагы таныклыкның күрсәткечләрен идентификацияләү процедурасына каршы килә торган дөрес булмаган (җитәрлек булмаган) белешмәләр бирү; | “Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы,<br>Россия Федерациясе Мәгариф |

| | | |
|---|---|---|
| тулы исемлеге | - Оешмага кабул ителүче балаларның иң күп яшендәге баланың яшен арттыру;<br>Муниципаль мәгариф оешмасына кабул итүдә анда буш урыннар булмау сәбәпле генә кире кагылырга мөмкин, моңа «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә һәм 88 статьяларында каралган очраклар керми.<br>Муниципаль мәгариф оешмасында урыннар булмаган очракта, баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) аны башка гомуми белем бирү оешмасына урнаштыру мәсьәләсен хәл итү өчен турыдан-туры «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУга мөрәҗәгать итә | һәм фән министрлыгының “Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында”гы 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы |

»;

1.2. 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен биналарда муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган муниципаль хезмәт турында мәгълүмат стендлары урнаштырыла. Бинаның алгы өлешенә мәгариф белән идарә итүнең муниципаль органы исеме турында мәгълүмат урнаштырыла.<br>Мөрәҗәгать итүчеләргә документларны рәсмиләштерү мөмкинлеге булган урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырылган урыннар бирелә.<br>Бина санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә җиһазландырылган булырга тиеш, шул исәптән күрсәтелгән объектларда инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларга уңайлылык тәэмин ителә | “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 2010 елның 27 июнендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы |

»;

1.3. 5.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) күпфункцияле үзәкләрдә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гарызнамәне теркәү срогы бозылу, мөрәҗәгать итүче бер тапкыр мөрәҗәгать иткәндә ике һәм аннан күбрәк муниципаль хезмәт күрсәтүләрне соратып алу;».

2. “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесенә (О.В. Купцова) әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында - http://chistopol.tatarstan.ru/ һәм хокук мәгълүматының рәсми интернет-порталында https://pravo.tatarstan.ru//

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары - Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы О.В. Купцовка йөкләргә.

Башкарма комитеты
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов